ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
СПАС
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СПАССКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

КАРАР ПОСТАНОВЛЕНИЕ

№ 20 2019 ел, 17 гыйнвар

**Спас муниципаль районы Башкарма комитетының «Спас муниципаль районы территориясендә мәктәпкәчә гомуми, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү мәгариф программалары буенча укытылырга тиешле балаларны исәпкә алу тәртибен раслау турында» 2017 елның 1 мартындагы 112 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында карары**

Спас муниципаль районында мәгариф өлкәсендәге вәкаләтләрне бүлешү турында Спас муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе карары белән расланган нигезләмәгә туры китереп, Спас муниципаль районында мәгариф өлкәсендәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыру максатыннан, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2019 елның 15 гыйнварындагы 271/19 номерлы методик киңәшләре нигезендә, ТР Спас муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Спас муниципаль районы Башкарма комитетының «Спас муниципаль районы территориясендә мәктәпкәчә гомуми, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү мәгариф программалары буенча укытылырга тиешле балаларны исәпкә алу тәртибен раслау турында» 2017 елның 1 мартындагы 112 номерлы карарына балаларны исәпкә алу һәм хисап формаларын тапшыру эшен оештыру өлешендә үзгәреш кертергә һәм аны яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Бу Карар үтәлешен контрольдә тотуны Спас муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Е.А. Афоньшинага йөкләргә.

ТР Спас муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе В.А.Осокин

Спас муниципаль районы Башкарма
комитеты җитәкчесенең 2019 елның
17 гыйнварындагы 20 номерлы
карарына кушымта

**Спас муниципаль районы территориясендә мәктәпкәчә гомуми, башлангыч гомуми, урта гомуми белем бирү мәгариф программалары буенча укытылырга тиешле балаларны исәпкә алу тәртибе**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Спас муниципаль районы территориясендә мәктәпкәчә гомуми, башлангыч гомуми, урта гомуми белем бирү мәгариф программалары буенча укытылырга тиешле балаларны исәпкә алу тәртибе (алга таба – Тәртип) Россия Федерациясе Конституциясенә, «Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын булдырмау системасы нигезләре турында» 1999 елның 24 июнендәге 120-ФЗ номерлы федераль законга, «Персональ мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы федераль законга туры китереп һәм Спас муниципаль районы территориясендә мәктәпкәчә гомуми, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү мәгариф программалары буенча укытылырга тиешле балаларны ел саен персональ исәпкә алуны (алга таба – балаларны исәпкә алу), балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын булдырмауны тормышка ашыру максатыннан эшләнде.

1.2. Тәртип «Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә балаларны исәпкә алуны уздыруда катнашучы учреждениеләр һәм оешмаларның үзара хезмәттәшлеге системасын билгели.

1.3. Аларның гомуми белем алуга Конституциядә язылган хокукларын тәэмин итү максатыннан, муниципаль берәмлек территориясендә яшәүче (даими яки вакытлыча) яки торучы 0дән алып 18 яшькә кадәрге барлык балалар, яшәү (тору) урынында теркәлүе булуга (булмауга) бәйсез рәвештә, мәҗбүри рәвештә ел саен исәпкә алынырга тиеш.

1.4. Беркетелгән территориядә теркәлгән 0дән алып 6 яшь тә 6 айга кадәрге балаларны ачыклауны һәм исәпкә алуны, Спас муниципаль районының авыл һәм шәһәр җирлекләре Башкарма комитетлары, Спас муниципаль районындагы социаль яклау органы, пенсия тәэминаты органы, опека һәм химаячелек органы белән үзара хезмәттәшлек итеп, мәктәпкәчә белем бирү оешмалары башкара.

1.5. Беркетелгән территориядә теркәлгән 6 яшь тә 6 айдан алып 18 яшькә кадәрге балаларны ачыклауны һәм исәпкә алуны, Спас муниципаль районының авыл һәм шәһәр җирлекләре Башкарма комитетлары, Спас муниципаль районындагы социаль яклау органы, пенсия тәэминаты органы, опека һәм химаячелек органы белән үзара хезмәттәшлек итеп, гомуми белем бирү оешмалары башкара.

1.6. Балаларны исәпкә алу буенча бу Тәртип нигезендә тупланучы мәгълүмат,

аның конфиденциальлеген тәэмин итә торган тәриптә, «Персональ мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы федераль законга туры китереп җыелырга, сакланырга һәм файдаланылырга тиеш.

**1. Балаларны исәпкә алу эшен оештыру**

2.1. Балаларны исәпкә алу эшенә методик һәм оештыру ягыннан җитәкчелекне «Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф бүлеге» МУ башкара.

2.2. Муниципаль берәмлек территориясендә балаларны исәпкә алу 0дән алып 18 яшькә кадәрге балалар турында «Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф бүлеге» МУ тарафыннан формалаштырылучы бердәм мәгълүмат базасын булдыру һәм алып бару юлы белән башкарыла.

2.3. Исәпкә алынырга тиешле балалар турында мәгълүмат базасын төзегәндә, түбәндәгеләр файдаланыла:

**2.3.1. Мәктәпкәчә белем бирү оешмалары мәгълүматлары:**

- Беркетелгән территориядә теркәлгән һәм (яки) яшәүче, мәктәпкәчә белем бирү оешмасына йөрүче 0дән алып 6 яшь тә 6 айга кадәрге балалар турында белешмәләр **(1 нче форма);**

- Беркетелгән территориядә теркәлгән һәм (яки) яшәүче, мәктәпкәчә белем бирү оешмасына йөрмәүче 0дән алып 6 яшь тә 6 айга кадәрге балалар турында белешмәләр. Бу исемлекләр статистика һәм район хастаханәсе мәгълүматларын исәпкә алып төзелә **(2 нче форма);**

**2.3.2. Гомуми белем бирү оешмалары мәгълүматлары:**

- Беркетелгән территориядә теркәлгән һәм (яки) яшәүче, гомуми белем бирү оешмасында укучы 6 яшь тә 6 айдан алып 18 яшькә кадәрге балалар турында белешмәләр **(3 нче форма);**

- Беркетелгән территориядә теркәлгән һәм (яки) яшәүче, гомуми белем алмаучы 6 яшь тә 6 айдан алып 18 яшькә кадәрге балалар (шул исәптән агымдагы елда беренче сыйныфка кабул ителергә тиешле 6 яшь тә 6 айдан алып 8 яшькә кадәрге балалар) турында белешмәләр **(4 нче форма);**

2.4. **«Спас муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф бүлеге» муниципаль учреждениесе мәгълүматлары:**

2.4.1. Беркетелгән территориядә теркәлгән, гаиләдә белем алу һәм мөстәкыйль белем алу формасында гомуми белем алучы 6 яшь тә 6 айдан алып 18 яшькә кадәрге балалар турында белешмәләр агымдагы елның 5 октябренә һәм 31 маена булган халәттә **(5 нче форма).**

2.5. Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларының һәм гомуми белем бирү оешмаларының рәсми мөрәҗәгатьләре буенча, **авыл һәм шәһәр җирлекләренең Башкарма комитетлары мәгариф оешмасына беркетелгән территориядә теркәлгән балаларның исемлекләрен (алга таба – балалар исемлекләре) бирә**:

- 0дән алып 18 яшькә кадәрге (кертеп) (авыл (шәһәр) җирлеге башлыгы имзасы куелган һәм мөһер белән расланган) **(6 нчы форма).**

2.6. **Агымдагы елның 5 октябренә «Спас муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф бүлеге» МУ, мәгариф оешмаларының хисапларына таянып,** «Гомуми белем бирү программалары буенча укытылырга тиешле балаларны исәпкә алу буенча Спас муниципаль районының мәгариф картасы» **(7 нче форма) җыелма хисабын төзи**. **Бу форма ОО-1 статистика күзәтүләре формалары белән бергә тапшырыла.**

2.7. 1-6 номерлы формалар буенча бирелә торган белешмәләр дөрес мәгълүматлардан торырга тиеш.

2.8. «Аерым категория» графасын тутыру балаларның аерым категориясен документ белән раслау нигезендә башкарыла. Ул булмаганда һәм балаларның ата-аналары (законлы вәкилләре) балаларның аерым категориясен раслаучы документларны күрсәтергә ризалашмаганда, мәктәпкәчә оешмалар һәм гомуми белем бирү оешмалары Спас муниципаль районындагы социаль яклау органына, пенсия тәэминаты органына, опека һәм химаячелек органына балаларның аерым категориясен раслау турында рәсми мөрәҗәгать җибәрә.

2.9. «Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф бүлеге» МУ мәктәпкәчә оешмалардан һәм гомуми белем бирү оешмаларыннан мәгълүматларны билгеләнгән срокларда, Спас муниципаль районының авыл һәм шәһәр җирлекләре Башкарма комитетлары тарафыннан тапшырылучы кушымта итеп бирелүче формалар буенча кабул итә.

3. Бу Тәртипкә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү Спас муниципаль районы Башкарма комитетының норматив актларын кабул итеп башкарыла.

**1 нче форма**

## Беркетелгән территориядә теркәлгән һәм (яки) яшәүче, мәктәпкәчә белем бирү оешмасына йөрүче 0дән алып 6 яшь тә 6 айга кадәрге балалар турында белешмәләр

______________________________________________

(мәгълүматларны җибәрүче мәктәпкәчә белем бирү оешмасының атамасы)

| Т-п № | Фамилиясе Исеме Атасының исеме | Туган көне (тулысынча) | Теркәлү адресы (тулысынча) | Яшәү адресы (тулысынча) | Аерым категория |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| | | | | | |

МББУ җитәкчесе ______ __________________ ___________________

(имза) (Ф. И. А.) (дата)

М. У.

Искәрмә: форма ел саен, агымдагы елның 1 гыйнварына һәм 1 сентябренә булган халәттә агымдагы елның 20 гыйнварына һәм 20 сентябренә кадәр тапшырыла.

«Аерым категория» графасы кодлаштырылган ысул белән тутырыла: 1 – инвалид балалар; 2 – сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән; 3 – ятим балалар; 4 – ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар.

**2 нче форма**

**Беркетелгән территориядә теркәлгән һәм (яки) яшәүче, мәктәпкәчә белем бирү оешмасына йөрмәүче 0дән алып 6 яшь тә 6 айга кадәрге балалар турында белешмәләр**

______________________________________________________________

(мәгълүматларны җибәрүче мәктәпкәчә белем бирү оешмасының атамасы)

| Т-п № | Фамилиясе Исеме Атасының исеме | Туган көне (тулысынча) | Теркәлү адресы (тулысынча) | Яшәү адресы (тулысынча) | Аерым категория |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| | | | | | |

МББУ җитәкчесе ______ (имза) ________________ (Ф. И. А.) __________________ (дата)

М. У.

Искәрмә: форма ел саен, агымдагы елның 1 гыйнварына һәм 1 сентябренә булган халәттә агымдагы елның 20 гыйнварына һәм 20 сентябренә кадәр тапшырыла.

«Аерым категория» графасы кодлаштырылган ысул белән тутырыла: 1 – инвалид балалар; 2 – сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән; 3 – ятим балалар; 4 – ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар.

**3 нче форма**

## Беркетелгән территориядә теркәлгән һәм (яки) яшәүче, гомуми белем бирү оешмасында укучы 6 яшь тә 6 айдан алып 18 яшькә кадәрге балалар турында белешмәләр

________________________________________________________________

(мәгълүматларны җибәрүче гомуми белем бирү оешмасының атамасы)

| Т-п № | Фамилиясе<br>Исеме<br>Атасының исеме | Туган көне (тулысынча) | Теркәлү адресы (тулысынча) | Яшәү адресы (тулысынча) | Сыйныф | Аерым категория |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| | | | | | | |

Җитәкче ______ __________________ ___________________

(имза) (Ф. И. А.) (дата)

М. У.

Искәрмә: форма ел саен, агымдагы елның 1 сентябренә булган халәттә агымдагы елның 20 сентябренә кадәр тапшырыла. Балаларның исемлекләре сыйныфлар буенча төзелә.

«Аерым категория» графасы кодлаштырылган ысул белән тутырыла: 1 – инвалид балалар; 2 – сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән; 3 – ятим балалар; 4 – ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар.

**4 нче форма**

## Беркетелгән территориядә теркәлгән һәм (яки) яшәүче, гомуми белем алмаучы 6 яшь тә 6 айдан алып 18 яшькә кадәрге балалар (шул исәптән агымдагы елда беренче сыйныфка кабул ителергә тиешле 6 яшь тә 6 айдан алып 8 яшькә кадәрге балалар) турында белешмәләр

________________________________________________________________

(мәгълүматларны җибәрүче гомуми белем бирү оешмасының атамасы)

| Т-п № | Фамилиясе Исеме Атасының исеме | Туган көне (тулысынча) | Теркәлү адресы (тулысынча) | Яшәү адресы (тулысынча) | Баланың укымау сәбәбе |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| | | | | | |

Җитәкче ______ ________________ _________________

(имза) (Ф. И. А.) (дата)

М. У.

Искәрмә: форма ел саен, агымдагы елның 1 сентябренә булган халәттә агымдагы елның 20 сентябренә кадәр тапшырыла. Балаларның исемлекләре туган еллары буенча алфавит тәртибендә төзелә.

**5 нче форма**

## Мәгариф оешмаларыннан читтә гаиләдә белем алу һәм мөстәкыйль белем алу формасында гомуми белем алучы балалар турында белешмәләр

**Спас муниципаль районы буенча**

______________________________________________

территориянең (муниципаль районның/шәһәр округының) атамасы

**________ елның 5 октябренә һәм 31 маена булган халәттә**

| Т-п № | Узу өчен кайсы мәгариф оешмасына беркетелгән | | Баланың фамилиясе, исеме, атасының исеме | Туган көне һәм елы | Сый-ныф | Гаиләдә белем алу формасында укуга күчкәнче, кайсы мәгариф оешмасында укыган | Гаиләдә белем алу формасында уку ничәнче елда башланган | Гаиләдә белем алу формасында программаны ничә ел үзләштерә | Гаиләдә белем алу формасына күчү сәбәпләре |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | арадаш аттестацияне | дәүләт йомгаклау аттестациясен | | | | | | | |
| **башлангыч гомуми белем бирү мәгариф программасы буенча** | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | |
| **төп гомуми белем бирү мәгариф программасы буенча** | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | |
| **урта гомуми белем бирү мәгариф программасы буенча** | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | |

Җитәкче ______________ ______________ ______________

(имза) (Ф. И. А.) (дата)

М. У.

**6 нчы форма**

______________________________________________

(исемлекләрне бирүче авыл (шәһәр) җирлеге Башкарма комитеты атамасы)

## территориясендә теркәлгән 0дән алып 18 яшькә кадәрге балаларның исемлекләре

| Т-п № | Фамилиясе | Исеме | Атасының исеме | Туган көне (тулысынча) | Теркәлү адресы (тулысынча) | Яшәү адресы (тулысынча) |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| | | | | | | |

Авыл (шәһәр) җирлеге башлыгы ____________________ ____________________ ________________

(имза) (Ф. И. А.) (дата)

М. У.

Искәрмә: форма ел саен, агымдагы елның 1 сентябренә булган халәттә агымдагы елның 20 сентябренә кадәр тапшырыла. Балаларның исемлекләре 9 нчы сыйныфны тәмамлаганнар өчен аерым, 11 нче сыйныфны тәмамлаганнар өчен аерым, алфавит тәртибендә төзелә.

**7 нче форма**

## Гомуми белем бирү программалары буенча укытылырга тиешле балаларны исәпкә алу буенча Спас муниципаль районының мәгариф картасы

| Яшь (белем бирү программасы атамасы) | Барлык балалар: графа 2 = 3 һәм 4 графаларның суммасы; графа 2 = 5, 6, 7, 10 һәм 13 графаларның суммасы | Муниципаль берәмлекләрдә (МБ) теркәлгән | Теркәлмәгән, ләкин муниципаль берәмлекләрдә (МБ) яшиләр | Укыйлар | укыйлар | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | Белем бирү эшчәнлеге алып баручы оешмаларда укыйлар | белем бирү эшчәнлеге алып баручы оешмалардан читтә | | | | | | | | |
| | | | | | | Муниципаль берәмлекләрдәге (МБ) мәгариф оешмаларына (МО) беркетелгән | Шулардан | | **ТРдагы** мәгариф оешмаларына (МО) беркетелгән | Шулардан | | РФдәге мәгариф оешмаларына (МО) беркетелгән | Шулардан | |
| | | | | | | | Гаиләдә белем алу | Мөстәкыйль белем алу | | Гаиләдә белем алу | Мөстәкыйль белем алу | | Гаиләдә белем алу | Мөстәкыйль белем алу |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 |
| 1 яшькә кадәр | | | | | | | | х | | | х | | | х |
| 2 яшькә кадәр | | | | | | | | х | | | х | | | х |
| 3 яшькә кадәр | | | | | | | | х | | | х | | | х |
| 4 яшькә кадәр | | | | | | | | х | | | х | | | х |
| 5 яшькә кадәр | | | | | | | | х | | | х | | | х |
| 6 яшькә кадәр | | | | | | | | х | | | х | | | х |
| 7 яшькә кадәр | | | | | | | | х | | | х | | | х |
| 7 яштән өлкәнрәк (8 яшькә кадәр) | | | | | | | | х | | | х | | | х |
| **Мәктәпкәчә белем бирү программасы буенча барлыгы** | | | | | | | | **х** | | | **х** | | | **х** |

| | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 сыйныф | | | | | | | | x | | | x | | | x |
| 2 сыйныф | | | | | | | | x | | | x | | | x |
| 3 сыйныф | | | | | | | | x | | | x | | | x |
| 4 сыйныф | | | | | | | | x | | | x | | | x |
| **Башлангыч гомуми белем бирү программасы буенча барлыгы** | | | | * | | | | x | | | x | | | x |
| 5 сыйныф | | | | | | | | x | | | x | | | x |
| 6 сыйныф | | | | | | | | x | | | x | | | x |
| 7 сыйныф | | | | | | | | x | | | x | | | x |
| 8 сыйныф | | | | | | | | x | | | x | | | x |
| 9 сыйныф | | | | | | | | x | | | x | | | x |
| **Төп гомуми белем бирү программасы буенча барлыгы** | | | | * | | | | x | | | x | | | x |
| 10 сыйныф | | | | | | | | | | | | | | |
| 11 сыйныф | | | | | | | | | | | | | | |
| **Урта гомуми белем бирү программасы буенча барлыгы** | | | | | | | | | | | | | | |
| **Барлык балалар** | | | | * | | | | | | | | | | |

* бу категория булганда, 7 нче таблица тутырыла.

Файдаланылучы кыскартулар: МО – мәгариф оешмалары; МБ – муниципаль берәмлекләр (район, шәһәр)

МБМУ җитәкчесе

________________ ____________________

(имза) (Ф.И.А.)

М.У.